МАМАДЫШ-АКИЛОВСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАМАДЫШ-ӘКИЛ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Мамадыш-Әкил ав. **КАРАР**

**«31» январь 2025 ел** **№ 5**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары нигезендә Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025 елның 01 февраленнән Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9 165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 01 февраленнән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2024 елның 02 февралендәге 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында .http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм шулай ук Мамадыш-Әкил авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин ур., 50 йорт (җирлек администрациясе бинасы); Татар Танай авылы, Үзәк урамы, 1а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы); Паново авылы, Үзәк бина, 26в йорт (авыл клубы).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 01.02.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

Мамадыш-Әкил
авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Мирхәтуллин

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш
Әкил авыл җирлеге башкарма комитеты
2025 елның 31 гыйнварындагы №5 карарына

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2025 елга

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәтләр бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 994,68 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1 422,81 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 747,88 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |

2 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Мамадыш
Әкил авыл җирлеге башкарма комитеты
2025 елның 31 гыйнварындагы №5 карарына

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2025 елга

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Тәннең киеме | 882,44 |
| 3. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 112,25 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1 422,81 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 2 747,87 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |